ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында” Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

## 1 статья

“Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында” 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Гыйбадәт кылулар, башка дини йолалар һәм тантаналар түбәндәгеләрдә тоткарлыксыз башкарыла:

гыйбадәт урыннарында, биналарында һәм корылмаларында, шулай ук мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрендә;

дини оешмаларның милек хокукындагы яисә аларның устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен аларга башка мөлкәт хокукында бирелгән биналарда һәм корылмаларда, шулай ук мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрендә;

дини оешмаларның милек хокукындагы яисә аларның устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен аларга башка мөлкәт хокукында бирелгән урыннарда, шулай ук, тиешле урыннары булган биналарның милекчеләре белән килештереп, мондый биналар урнашкан җир кишәрлекләрендә;

дини оешмалар төзегән оешмаларның милек хокукындагы яисә аларга башка мөлкәт хокукында бирелгән урыннарда, биналарда, корылмаларда һәм җир кишәрлекләрендә;

дини оешмаларның милек хокукындагы яисә аларга башка мөлкәт хокукында бирелгән җир кишәрлекләрендә;

гыйбадәт кылу урыннарында;

зиратларда һәм крематорийларда;

торак урыннарда.”;

2) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Башка очракларда җәмәгать урыннарында җәмәгать тәртибен һәм дини йолаларда һәм тантаналарда катнашучыларның да, башка гражданнарның да иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны таләп итә торган шартларда үткәрелә торган гавами гыйбадәт кылулар, башка дини йолалар һәм тантаналар (гыйбадәт кылу җыелышларын һәм дини җыелышларны кертеп) митинглар, урам йөрешләре һәм демонстрацияләр уздыру өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2015 елның 16 гыйнвары
№ 1-ТРЗ